УДК 94(47)

***Р.И. Беккин***

# ГАТАУЛЛА БАЯЗИТОВНЫҢ СОҢГЫ ГОЗЕРЕ

Предлагаем вниманию читателей два документа – письмо генерал-лейтенанта Губайдуллы Чингисхана к М.А. Гамазову от 23 сентября 1888 г. и письмо Атауллы Баязитова к иранисту В.А. Жуковскому. Второе письмо уникально тем, что представляет собой возможно последний документ, написанный или, если быть точным, продиктованный Баязитовым. Само письмо, датируемое 19 апреля 1911 г., написано рукой писаря, но под ним стоит автограф ахуна. А. Баязитов скончался после неудачно проведенной операции в ночь на 22 апреля. Автор письма предвидел такой исход, и эти мысли послужили поводом обратиться к Жуковскому с письмом.

**Ключевые слова:** Атаулла Баязитов, Губайдулла Чингисхан, М.А. Гамазов, В.А. Жуковский, мусульмане Петербурга.

Россиядә ислам тарихын өйрәнә торган һәр тикшеренүче өчен иң кызыклы мәсьәләләрнең берсе – мөгаен, мөселманнарның рус җәмгыятендәге күренекле шәхесләр белән элемтәләре. Ләкин бу мәсьәлә өстендә эшләгән галим өчен иң кыены – материал җитмәү. Хатлар, истәлекләр һәм башка чыганакларда мөселманнарны сирәк кенә телгә алу картинаны ачып бетерми. Ә сүз бит, башлыча, мөселман халыклы регионнар турында бара (мәсәлән, Кырым, Кавказ, Идел буе, Урта Азия). Империянең башкаласы, XIX–XX гасырлар чигендә 5 меңнән артык мөселман яшәгән Петербург турында әйтсәк, анда мөселманнарның шәһәрдәге башка милләт вәкилләре белән бәйләнешләре турында мәгълүматны бөртекләп җыярга кирәк. Әлбәттә, бу күбрәк рус телле чыганакларга карый, ләкин мөселман халыклары телләрендә булган документларда да шундый ук хәл күзәтелә.

Мәгълүматның аз булуы кайбер авторларның расланган фактларга нигезләнми генә, дәлилләнмәгән мәгълүмат, уйдырмалар куллануына китерә. Нәтиҗәдә мифлар барлыкка килә; алар исә, бернинди аңлатма, шәрехләрсез генә, компилятор тикшеренүчеләрнең бер хезмәтеннән икенчесенә күчеп йөри.

Шундый мифларның берсе – Петербург ахуны Г. Баязитов һәм философ Вл. Соловьев арасында булган якын дустанә мөнәсәбәтләр турындагысы – безнең бер мәкаләдә җентекләп тикшерелгән иде [Беккин, б. 88–104]. Бу ике фикер иясе арасындагы мөнәсәбәтләрне тикшерү белән генә чикләнмичә, без шул ук мәкаләдә Баязитовның Петербург җәмгыятенең башка вәкилләре белән дә бәйләнешен карап узган идек. Ахун озак еллар буе тыгыз элемтәдә торган шәхесләрнең берсе – аның турыдан-туры җитәкчесе, Тышкы эшләр

министрлыгының Азия департаменты Шәрык телләрен укыту бүлеге башлыгы, шәрык белгече Матвей Авелевич Гамазов[1].

1880 елда Г. Баязитов Тышкы эшләр министрлыгына тәрҗемәче (драгоман) буларак чакырыла, ә 1888 елда, М.А. Гамазов тәкъдиме белән, коллеж регистраторы чинында төрки телләр мөгаллиме итеп билгеләнә. Шулай итеп, Г. Баязитов Петербургның икенче мөселман мәхәлләсе имамы эшләрен дәүләт хезмәте белән бергә алып бара.

Генерал-лейтенант Гобәйдулла Чынгызханның М.А. Гамазовка язган хаты нәкъ шул чорга карый. Хат 1888 елның 23 сентябрендә язылган. Бу документ эчтәлеге һәм машинкада бастырылуы белән дә кызыклы. 1888 елда андый бастырылган хатлар әле сирәк күренеш була. Шуңа күрә дә хат башында Чынгызхан аңлатма биреп китә: «Басма хәрефләр белән язуыма гаҗәпләнмәгез, бүген шундый машина уйлап чыгарганнар, тиз язарга була, һәм ул мине инде күпмедер вакыт юата» [Письмо Чингис-хана Тору М.А. Гамазову].

Эчтәлеге һәм интонациясе ягыннан дусларча язылган әлеге хат, әлбәттә, безнең игътибарны бу факт белән генә җәлеп итмәде. Баязитов фамилиясе ачыктан-ачык әйтелмәсә дә, күптән түгел генә билгеләнгән мөгаллим турында сүз барганда, Чынгызханның ахун турында сөйләве бәхәссез: «Сез сайлаган кеше – мөгаллим турында. Хаталанмадыгыз, ул сезнең ихтирамны яулар өчен күп көч куяр дип өметләнәм» [шунда ук][2]. Чыңгызханның, күпчелек тормышын Петербургта яшәгән мөселман кешесе буларак, Баязитовны белми калуы мөмкин түгел. Бу бәхәссез. Бәлки тәрҗемәче һәм Азия департаментына мөгаллим буларак ахунны да Гамазовка ул тәкъдим иткәндер.

Матвей Авелевичны Г. Баязитовның мөгаллим буларак хезмәте канәгатьләндергәндер дә, ләкин аның фәнни тикшеренүләре шәрык белгечендә яклау тапмый. Аннан тыш, Баязитовның галим-тикшеренүче буларак чыгышларын Гамазов ачыктан-ачык көлкегә дучар итә [бу турыда тәфсилләбрәк кара: Беккин, б. 96–97].

Г. Баязитовка, ислам канунnарын, шәрык телләрен әйбәт белү өстенә, европача белемлелек җитми. Европа белеме фән өлкәсенә юлны киңәйтә, андый белемгә ия кеше колониаль галимнең җирле халык арасыннан булган кече ярдәмчесе генә түгел, ә тулы хокуклы партнеры була ала. Мәшһүр татар галиме Хөсәен Фәезханов мисалы бу хакыйкатьне яхшы раслый. Әгәр дә Баязитовның амбицияләре башкаланың бер мөселман мәхәлләсе җитәкчесе булу белән генә чикләнсә, аңа үзендә булган әйбәт дини белем бик

[1] Гамазов Матвей Авелевич (1812–1893) – Россия дипломаты, шәрык белгече, Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаменты Шәрык телләрен укыту бүлеге башлыгы (1872–1893).

[2] Югарыда күрсәтелгәнчә, 1888 елда Г. Баязитов Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаменты Шәрык телләрен укыту бүлегендә төрки телләр мөгаллиме итеп билгеләнә.

җиткән булыр иде. Россия империясе шартларында имамнарның, Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаменты хезмәткәрләре кебек үк, дәүләт чиновниклары булуын да истә тотарга кирәк. Ләкин Баязитов имам булу белән генә канәгать түгел. 1871 елда Петербургка килгәннән бирле ул хезмәт юлын акрынлап һәм зур тырышлык куеп киңәйтә, руханилык роле белән генә чикләми. Ләкин биредә аннан инде белемлелекнең бөтенләй башка дәрәҗәсе таләп ителә. Г. Баязитов моны яхшы аңлый һәм улы Мөхәммәдсафага киләчәктә мөхтәрәм дин башлыгы гына түгел, ә дөньяви яктан да хезмәт юлын уңышлы ясарлык белем бирергә омтыла.

Г. Баязитовның мәкаләдән соң китерелгән хаты Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаменты Шәрык телләре бүлеге башлыгы Валентин Алексеевич Жуковскийга[1] язылган.

Хатның эчтәлеге турында сүз башлаганчы, аның уникаль документ булуын әйтеп китәргә кирәк: бу хат Баязитов тарафыннан язылган, төгәлрәге, әйтеп яздырылган хатларның соңгысы булуы да ихтимал. 1911 елның 19 апрелендә язылган бу документ хаттат кулы белән язылган, ләкин ахырында Ахун автографы бар[2]. 21 апрельдә уңышсыз узган операциядән соң ахун бакыйга күчә. Хат авторы бу хәлнең булу мөмкинлеген яхшы аңлый, шуңа күрә дә Жуковскийга хат аша гозер белән мөрәҗәгать итә: «Ходайга тапшырдым, мин икенче тапкыр операциягә тәвәккәлләдем. Бу операциянең минем өчен соңгысы булуы да бар» [Письмо А. Баязитова к В.А. Жуковскому].

Хатта Г. Баязитов җитәкчесеннән улы Мөхәммәдсафа турында кайгыртуын сорый. Балалары үзеннән соң матди яктан тәэмин ителмичә калалар дип язса да, хатта сүз матди кайгырту турында бармый. Беренчедән, Мөхәммәдсафага әтисе үлгәндә 33 яшь була, һәм ул вакытта инде ул мөстәкыйль кеше. Икенчедән, яшәү өчен матди чаралар җитмәсә, М. Баязитов Касыйм татарлары арасыннан Петербургта яшәүче сәүдәгәрләргә мөрәҗәгать итә алыр иде (мәсәлән, Фатыйх Бәйрәшевкә). Ф. Бәйрәшев белән ул озак еллар дустанә мөнәсәбәттә була, хәтта алга таба бергәләп «Сират әл-мөстәкыйм» («Туры юл») уң партиясен оештыра. Г. Баязитов вафатыннан соң Петербургның икенче мөселман мәхәлләсе имамы урыны аның улына кала. Г. Баязитов, Жуковскийга гозер белән мөрәҗәгать итеп, Валентин Андреевич аның улына рус җәмгыятендә үз урынын алырга ярдәм итәр дип ышана. Бу эштә Мөхәммәдсафага бары тик Г. Баязитовны яхшы белгән рус чиновниклары гына ярдәм күрсәтә ала. Ахунның ышанычы чынга аша. Улына үзеннән соң мөселман мәхәлләсе һәм Россиядә беренче татар газе-

[1] Жуковский Валентин Алексеевич (1858–1918) – шәрык белгече, иранист, Санкт-Петербург университетының Шәрык телләре факультеты деканы (1902–1911), Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаменты Шәрык телләрен укыту бүлеге башлыгы.

[2] Ахунның русча язылган күпчелек хатлары хаттат тарафыннан язылган һәм аларда Баязитов имзасы гына тора.

тасы «Нур» гына түгел, ә матди булмаган, әмма Гатаулла Баязитов өчен аеруча мөһим һәм кадерле «байлык» кала: рус җәмгыятендә элемтәләр. Бу элемтәбагланышлар киләчәктә Мөхәммәдсафа Баязитовка Петербург һәм империянең башка ислам дин әһелләре арасында алга чыгарга мөмкинлек бирә. 1915 елда ул, мөселманнарның шактый өлеше тарафыннан яклау тапмаса да, Оренбург Диния нәзарәте мөфтие итеп билгеләнә.

**Әдәбият**

*Беккин Р.И.* Бер дуслык тарихы: Г. Баязитов һәм В.С. Соловьев // Фәнни Татарстан. 2016. № 3. Б. 88–104.

Письмо Чингис-хана Тору М.А. Гамазову // ОР РНБ. Ф. 172. Д. 121. Л. 1.

Письмо А. Баязитова к В.А. Жуковскому // АВ ИВР РАН. Ф. 17. Оп. 2. Д. 6. Л. 1.

**Чынгызхан Торуның М.А. Гамазовка язган хаты**[1]

Симферополь 23 сентября 1888 г.

Сейчас принесли с почты Ваше дорогой мне, Матвей Авелиевич, письмо от 5-го сего месяца. Искренно тронут вниманием и очень Вас благодарю.

Неудивляйтесь, что я пишу печатными буквами, ныне придумали такую машину, что можно скоро писать и притом она забавляет меня на некоторое время…

Очень рад, что Вы вводите у себя курс татарского языка, которым пользуется вся русская татария до Бухары. Что же касается до несочувствия одной личности, то этим тупоумием выскочки Вы не огорчайтесь. Результаты Ваших трудов в этом полезном деле, скоро его приведут в разумение…

От души желаю Вам полного успеха. Относительно избранника Вашего – учителя, он же вновь испеченный чин я надеюсь Вы неошиблись в нем, он будет очень стараться заслужить Ваше спасибо».

Погода у нас – великолепная – просто лето. Такой теплыни здесь, незапомнят и старожилы… За то вы? На севере холода говорят проезжающие на южный берег лица ежедневно с курьерскими поездами, которых я встречаю ежедневно в 8 ч. утра… Все они стремятся в Ялту, Гурзуф и тому подобн. российским курортным местам, но увы? там их ждет полный грабеж местных кулаков-хозяев… Так что холод севера иным приезжим показывается краше южных «экономических» апетитов Ялтинских дач и домо-владельцев. Короче для примера – винограда 1 фунт стоит в Ялте – 25 коп. тогда как Виноградары продают пуд за 1 р. 75 к. на базаре тем же ялтинским вампирам… Исключение быть может, но совсем на других основаниях…

Если Вы напр. Занимаете видное положение в ПБГ[2] и на вас можно расчитывать по делам такого проприетера то Вам все будет за даром…

[1] Хатлар оригинал орфографиясен һәм пунктуациясен саклаган хәлдә тәкъдим ителә.

[2] Санкт-Петербург күздә тотыла.

Недурна ведь тактика этих вампиров? Какого же бедному и больному люду которому не развлечения влекут сюда, а лечение от злой болезни…

Однако я навеял на Вас скуку… Простите дорогой мой Матвей Авелиевич за откровенность.

Целую Вас крепко.

Ваш старый слуга.

Чингис-Хан Тору

приложил
Тугра.

При случае засвидетельствуйте Ивану Алексеевичу мой глубокий селям. Не вздумал ли он поехать «купаться» в Каспийском море? Там кажется в нынешний сезон появился «особенный» – шефкет? … Ха Ха Ха

Скажите пожалуйста что за мода нынче печатать в газетах какие-то документы? То они подложные, то подлинные… Кажись господину железному канцлеру приходится страдать от ржавчины. Да, просто заржавел старик… Ина мудреца находит простата своя… Поживем увидим… Кланяюсь

(ОР РНБ. Ф. 172. Д. 121. Л. 1-1об.)

**Г. Баязитовның В.А. Жуковскийга язган хаты (1911 елның 19 апреле)**

19 апреля 1911 г.

Глубокоуважаемый Валентин Алексеевич!

Уповая Господу Богу я решился вторично идти на операцию. Может случиться, что операция эта будет роковой для меня. Поэтому я пишу Вашему превосходительству последнее мое письмо. На смертном одре я приношу Вам и уважаемой Варваре Алексеевне мою глубочайшую благодарность и признательность за все те милости, которые Вы и Варвара Алексеевна оказали мне.

Затем, глубокоуважаемый Валентин Алексеевич, в виду того, что моя семья – дети совершенно не обеспечены, я обращаюсь к Вам с моей последней просьбой: не оставьте моего сына Сафу. Он совершенно благонадежный человек, на него можно положиться. Восточную литературу, мусульманскую богословие он знает прекрасно, нисколько не меньше меня самого. Об европейском образовании его Вам известно самим. Поэтому прошу Вас, глубокоуважаемый Валентин Алексеевич, не оставьте моих детей, примите моего сына Сафу на мое место в должность драгомана. Тогда бы я спокойно закрыл глаза. Еще раз благодарю Вас и глубокоуважаемую Варвару Алексеевну.

Признательный Вам Ахунд Баязитов»

(АВ ИВР РАН. Ф. 17. Оп. 2. Д. 6. Л. 1)

***Беккин Ренат Ирек улы,***
*икътисад фәннәре докторы, Россия Фәннәр академиясе профессоры,*
*Россия Фәннәр академиясе Африка институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*



254. 19 Апреля 1911 г. 131

Глубокоуважаемый
Валентинъ Алексеевичъ!

Уповая Господу Богу я решился вторично идти на операцію. Можетъ случиться, что операція эта будетъ роковой для меня. Потому я пишу Вашему Превосходительству последнее мое письмо. На смертномъ одрѣ я приношу Вамъ и уважаемой Варварѣ Алексеевнѣ мою глубочайшую благодарность и признательность за всѣ тѣ милости, которыя Вы и Варвара Алексеевна оказали мнѣ. Затѣмъ, глубокоуважаемый Валентинъ Алексеевичъ, в виду того, что моя семья-дѣти совершенно не обезпечена, я обращаюсь къ Вамъ съ моей последней просьбой: не оставьте моего сына Сафу. Онъ совершенно благонадежный человѣкъ, на него можно положиться. Восточную литературу, мусульманское богословіе онъ знаетъ прекрасно, нисколько не меньше меня самого. Объ европейскомъ его образованіи ~~ему~~ его Вамъ извѣстно самимъ. Потому прошу Васъ, глубокоуважаемый Валентинъ Алексеевичъ, не оставьте моихъ дѣтей, примите моего сына Сафу на мое мѣсто въ должности драгомана. Тогда бы я спокойно закрылъ глаза. Еще разъ благодарю Васъ и глубокоуважаемую Варвару Алексеевну.

Признательный Вамъ Ахундъ А. Баязитовъ

ИВ АН СССР
Сектор Восточных Рукописей
Архив
Ф. 17
Оп.
№

Г. Баязитовның В.А. Жуковскийга язган хаты (1911 елның 19 апреле)



Симферополь 23 Сентября 1888г.

Сейчасъ принесли съ почты Ваше Дорогой мнѣ Матвій Авеліевичъ, письмо отъ 5 сего м-ца. Искренно тронутъ вниманіемъ и очень Васъ бдагодарю.

Неудивляйтесь, что я пишу печатными буквами; нынѣ придумали такую машину, что можно скоро писать и притомъ она забавляетъ меня на первое время.....

Очень радъ, что Вы вводите у себя курсъ татарскаго языка, которымъ пользуется вся русская татарія до Бухары. Что же касается до несочувствія одной личности, то этимъ тупоуміемъ выскочки Вы неогорчайтесь. Результаты Вашихъ трудовъ въ этомъ полезномъ дѣлѣ, скоро его приведутъ въ разумѣніе...

Отъ души желаю Вамъ полнаго успѣха. Относительно избранника Вашего-учителя, онъ же вновь испеченный чинъ я надѣюсь Вы неошиблись въ немъ; онъ будетъ очень стараться выслужить Ваше спасибо"

Погода у насъ -в е л и к о л ѣ п н а я -просто лѣто. Такой теплыни здѣсь, незапомнятъ и старожилы...За то вы ?? На сѣверѣ холода говорятъ проѣзжающія на южный берегъ лица ежедневно съ курьерскими поѣздами, которыхъ я встрѣчаю ежедневно въ 8 ч. утра...Всѣ они стремятся въ Ялту, Гурзуфъ и тому подоби. Россійскимъ курортнымъ мѣстамъ, но увы? тамъ ихъ ждетъ полный грабежъ мѣстныхъ кулаковъ-хозяевъ.... Такъ что холодъ сѣвера инымъ пріѣзжимъ показывается краше южныхъ "экономическихъ" апетитовъ Ялтинскихъ даче и домовладѣльцевъ. Короче для примѣра-винограда I фунтъ стоитъ въ Ялтѣ-25 коп. тогда какъ Виноградары продаютъ пудъ за 1р. 75к. на базарѣ тѣмъ же ялтинскимъ вампирамъ.... Исключеніе можетъ быть, но совсѣмъ на другихъ основаніяхъ..



Если Вы напр. занимаете видное положеніе въ ПБГ и на васъ можно расчитывать по дѣламъ такого пропріетера то Вамъ все будетъ за даромъ...Недурна вѣдь тактика этихъ вампировъ? Каково же бѣдному и больному люду которому не развлеченія влекутъ сюда, а леченіе отъ злой болезни....

....Однако я навѣялъ на Васъ скуку... Простите Дорогой мой Матвій Авеліевичъ за откровенность.

Цѣлую Васъ крѣпко.

Вашъ старый слуга
Чингисъ-ХанъТору
приложилъ

При случаѣ засвидѣтельствуйте Ивану Алексѣевичу мой глубокій селямъ. Невздумалъ ли онъ поѣхать "купаться" въ Каспійскомъ морѣ?Тамъ кажется въ нынѣшній сезонъ, появился "особенный"-шефкетъ? ...Ха Ха Ха

Скажите пожалуйста что за мода нынче печатать въ газетахъ какіе-то документы?То они подложные, то подлинные....Кажись господину желѣзному канцлеру приходится страдать отъ ржавчины.Да, просто заржавѣлъ старикъ...Ина мудреца находитъ простата своя...... Поживемъ увидимъ....Кланяюсь

Чынгызхан Торуның М.А. Гамазовка язган хаты